ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
“АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ “
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район,**
**село Старые Киязлы, ул. Центральная д.57**
**Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 1061665002332,**
**ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001**

КАРАР

№3 31 гыйнвар 2023 нче ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлегендә җирләү буенча
күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә 2023 нче елга бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлекнең иң чик күләмен әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 7793,48 (җиде мең җиде йөз туксан өч сум, 48 тиен) күләмендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварында 4 номерлы карарын 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайты http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Совет рәисе,
Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы Дәүләтшин Г.Г.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2023нче елдагы
3 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
Иске Кыязлы авыл җирлегендә 2023 нче елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә билгеләнгән бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3593,48 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1000 |
| 4. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3200 |
| Барлыгы | **7793,48** |

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2023нче елдагы
3 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының
Иске Кыязлы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә билгеләнгән бәясе 2023 елга

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе ( *сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.Кәфенләү | 500,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3093,48 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1000 |
| 5. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 3200 |
| Барлыгы | **7793,48** |